# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«22» 01 2021 ел Яр Чаллы №128

«2021-2023 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү» программасын раслау турында

2015-2030 елларга Россия Федерациясенең сәламәтлек саклау үсеше стратегиясе, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында», «Тәмәке тартуны чикләү турында» Федераль законнар, «2014-2021 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасы нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2021-2023 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү» район программасын кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары И.Ш. Бариевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның ___ 22.01 ___ 128 номерлы карарына кушымта

**«2021-2023 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү» программасы**

**Яр Чаллы шәһәре**
**2021 ел**

## ЭЧТӘЛЕГЕ

Программаның паспорты

Программаны тормышка ашыру сферасының гомуми характеристикасы.

Программаның максатлары һәм бурычлары

Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Тормышка ашыру механизмы

Программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү
(бәяләү индикаторлары)

Программаны тормышка ашыру буенча чаралар

# ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2021 - 2023 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү» (алга таба – Программа) |
| Дәүләт заказчысы | Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүче | Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| Программаны төп башкаручылар | - Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге;<br>- «Мәгариф идарәсе» МКУ;<br>- Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге;<br>-Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Тукай муниципаль районындагы социаль яклау идарәсе (килешү буенча);<br>- «Якты юл» («Светлый путь») район газетасы (килешү буенча);<br>- учреждениеләр, оешмалар, фондлар, иҗтимагый берләшмәләр (килешү буенча) |
| Программаның максаты | - Тукай муниципаль районы халкының уртача гомер озынлыгын һәм тормыш сыйфатын арттыру;<br>- Тукай муниципаль районы халкында, беренче чиратта, балалар, яшүсмерләр һәм яшьләр арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру;<br>- Халыкта үз сәламәтлегенә карата сакчыл мөнәсәбәт, сәламәт яшәү рәвешенә омтылыш формалаштыру;<br>- Социаль әһәмиятле авыруларны профилактикалау, гомуми авырулар санын киметү;<br>- Алкогольле продукция, сыра, тәмәке куллануны киметү;<br>- Алкогольле продукцияне чамадан тыш куллануны кисәтү системасының нәтиҗәлелеген арттыру |
| Программаның бурычлары: | Программа чаралары түбәндәге юнәлешләр буенча системалаштырыла:<br>- Тукай муниципаль районы халкы арасында тәмәке тарту күренешен һәм алкогольле эчемлекләрнең таралуын киметү;<br>- алкогольле эчемлекләр сату күләмен киметү, эшләүче гражданнарның сәламәтлеген саклау, сәламәтлек культурасын формалаштыру өлкәсендә иҗтимагый сәламәтлекне саклау системасын, физик культура һәм спортны, мәгарифне үстерү;<br>- яшәү, уку, хезмәт эшчәнлеге урыны буенча төрле категория халыкның физик культура, спорт белән шөгыльләнүе өчен уңайлы шартлар булдыру;.<br>- физик активлыкны һәм сәламәт яшәү рәвешен системалы пропагандалауны оештыру. |

| | |
|---|---|
| Программаны тормышка ашыру вакыты | 2021-2023 еллар |
| Еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп, Программаны финанслау күләме | 2021 - 2023 елларда программаны финанслауның гомуми күләме 5 502 000 сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>2021 елда - 1 834 000 сум;<br>2022 елда - 1 834 000 сум;<br>2021 елда - 1 834 000 сум<br>Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм тиешле елга һәм план чорына бюджет проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш.<br>Республика, федераль бюджеттан һәм бюджеттан тыш чыганаклардан средстволар ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк. |
| Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә 2023 елга түбәндәгеләр күздә тотыла:<br>- Тукай муниципаль районы халкының уртача гомер озынлыгын һәм тормыш сыйфатын арттыру;<br>- Тукай муниципаль районы халкында, беренче чиратта, балалар, яшүсмерләр һәм яшьләр арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру;<br>- халыкта үз сәламәтлегенә карата сакчыл мөнәсәбәт, сәламәт яшәү рәвешенә омтылыш формалаштыру;<br>- социаль әһәмиятле авыруларны профилактикалау, гомуми авырулар санын киметү;<br>- алкогольле продукция, сыра, тәмәке куллануны киметү;<br>- алкогольле продукцияне чамадан тыш куллануны кисәтү системасының нәтиҗәлелеген арттыру. |

## I. Программаны тормышка ашыру сферасының гомуми характеристикасы, шул исәптән программа хәл итүгә юнәлдерелгән проблемалар

«2021 - 2023 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында халык арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкогольле продукция, сыра һәм тәмәке куллануны киметү» муниципаль программасы сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруның бердәм системасын булдыру, бүгенге һәм киләчәк буыннарның сәламәтлегенең югары дәрәҗәсенә ирешү, халыкның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, кеше потенциалын саклап калу һәм үстерү, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы халкының уртача гомер озынлыгын һәм сыйфатын арттыру белән бәйле рәвештә эшләнде.

Сәламәтлек торышы - ул социаль, психик, икътисадый һәм экологик иминлекнең мөһим күрсәткече, халыкның тормыш сыйфаты билгесе.

Сәламәтлекнең торышына әйләнә-тирә мохитнең һәм җәмгыятьнең иминлеге, торак һәм туклану сыйфаты, тәмәке тарту таралу һәм алкоголь эчемлекләрне куллану, алкоголь эчемлекләрен, шул исәптән сыра сату күләме, тәмәке эшләнмәләрен сатып алу чыгымнары, физик культура белән шөгыльләнү мөмкинлеге, белем һәм керемнәр дәрәҗәсе кебек төрле факторлар йогынты ясый.

Халыкның сәламәтлек проблемасы социаль-икътисадый характерга ия:

беренчедән, халыкның сәламәтлек сыйфаты эшләүче гражданнарның хезмәт җитештерүчәнлегенә турыдан-туры йогынты ясый; икенчедән, эшләмәүче халык саны арту аркасында, эшкә яраклы халыкка эш йөкләмәсе арта, бу социаль киеренкелекнең сәбәбе булып тора һәм керемнәрнең кимүенә, шулай ук эшләүче кешеләрнең тормыш дәрәҗәсе начараюга итерә.

Халыкның сәламәтлеген ныгытуга һәм әйләнә-тирә мохитне савыктыруга юнәлдерелгән сәясәт формалаштыру, кешеләрнең үз сәламәтлекләренә һәм тирә-юньдәгеләрнең сәламәтлегенә җаваплы карашын булдыру аша халыкның һәм киләчәк буынының сәламәтлек дәрәҗәсен күтәрергә мөмкин. Әлеге проблемаларны хәл итү өчен комплекслы якын килү зарур: халыкның тормыш сыйфатына һәм сәламәтлегенә йогынты ясаучы төрле ведомстволар, барлык милек формаларындагы оешмалар һәм учреждениеләр, иҗтимагый оешмаларның көчләрен берләштерергә.

Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалаучы, сәламәт яшәү рәвеше, социаль реклама өлкәсендә белгечләр әзерләүче программа чараларын уңышлы үткәрү, нәтиҗәдә, шәһәрдә һәм районда медик-демографик хәлне яхшырачак. Районда яшәүчеләрнең сәламәт яшәү рәвеше алып баруы үлүчеләр саны кимүгә, шул исәптән хезмәткә яраклы халык арасында, төрле яшь төркемнәрендә, өлкәннәр арасында да, балалар арасында да авырулар санының кимүенә, инвалидлык буенча пенсиягә вакытыннан алда чыгу очракларының кимүенә, авыруларны кисәтүгә һәм башлангыч стадияләрдә ачыклауга йогынты ясаячак. Сәламәт яшәү рәвеше, сәламәтлек саклау өлкәсендәге югары күрсәткечләр үлүчеләр саны кимүгә һәм туучылар саны артуга китерәчәк, бу районда демографик вәзгыятькә уңай йогынты ясаячак.

Соңгы елларда спорт инфраструктурасы шактый яхшырды: Сосновый Бор поселогында «Яшьлек» универсаль спорт залы, Круглое Поле поселогында «Акчарлак» ябык йөзү бассейны, төрле торак пунктларда «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы нормативларын үтәүгә әзерлек өчен 16 яңа универсаль спорт мәйданчыгы һәм кече спорт мәйданчыгы төзелде һәм уңышлы файдаланыла. Яңа поселогының спорт залында капиталь ремонт ясалды. Быел Түбән Суыксу авылында «Алга» универсаль спорт залы һәм Новый поселогында 3 км озынлыкта яктыртылган чаңгы трассасы булган чаңгы базасы ачылды.

Ел саен районда, 10 меңнән артык кешене җәлеп итеп, 40 тан артык спорт-сәламәтләндерү чарасы үткәрелә. Районның гомуми белем бирү оешмалары, район үзәк хастаханәсе, «Чаллы-Бройлер» ААҖ, «Тукайтеплогаз», «Кама» агрофирмасы, «Ярыш», «Гигант», «Сәйдәш» АХП ҖЧҖ хезмәткәрләре, район халкы авыл җирлекләре командалары составында актив катнаша.

Катнашучылар өчен спортның иң популяр төрләре булып чаңгы ярышлары, волейбол, мини футбол, шашка, шахмат, алкалы хоккей тора.

Ел саен «Физик культура һәм спортны үстерүче иң яхшы гомуми белем бирү учреждениесе» конкурсы үткәрелә, аның нигезендә гомуми белем бирү мәктәпләре арасында спортның төрле төрләре буенча ярышларда катнашу буенча рейтинг алып барыла. Муниципаль ярышларда катнашып, иң яхшы нәтиҗәләр күрсәткән мәктәпләр балл системасы буенча бәяләнә. Җиңүчеләр, район мәгариф учреждениеләрендә укучылар санына карап, рейтинг таблицасында балларның иң аз суммасы буенча ике төркем буенча билгеләнә. Август конференциясендә әлеге мәктәпләр грамоталар һәм спорт инвентаре алу өчен сертификат белән бүләкләнә.

«Милләтләр кроссы», «Россия чаңгы юллары», ГТО фестивальләре кебек массакүләм Бөтенроссия чараларында да халык актив катнаша.

Бу чаралардан өлкән яшьтәге кешеләр һәм физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр дә читтә калмый. Шундый категория кешеләр өчен районда традицион рәвештә төрле спорт ярышлары махсус үткәрелә.

Болар барысы да район халкының күпчелегенә физик культура һәм спорт белән актив шөгыльләнергә, спорт нәтиҗәләрен яхшыртырга мөмкинлек бирә. 2019 ел нәтиҗәләре буенча физик культура һәм спорт белән актив шөгыльләнүче халык өлеше 47,34% тәшкил итте.

Әлеге программаны тормышка ашыруның финанс-икътисадый нәтиҗәсе булып эшкә яраклы халык саны арту, хасталык кәгазьләре буенча түләүләр кимү, эшкә яраксызлык, шул исәптән авыру балаларны карау вакыты кимү хисабына район бюджетына физик затлар керемнәренә салым керемнәренең артуы торачак.

Программаны тормышка ашыру барышында шулай ук ведомствоара хезмәттәшлек һәм социаль партнерлык көчәячәк, гражданлык җәмгыяте һәм халыкның районның социаль сәясәтен планлаштыруда һәм авыл инфраструктурасын үстерүдә катнашуы активлашачак.

## II. Программаның төп максатлары һәм бурычлары, программа чаралары, көтелгән ахыргы нәтиҗәләрне тасвирлау, тормышка ашыру вакыты

Программаның максатлары:

- Тукай муниципаль районы халкының уртача гомер озынлыгын һәм тормыш сыйфатын арттыру;
- Тукай муниципаль районы халкында, беренче чиратта, балалар, яшүсмерләр һәм яшьләр арасында, сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру;
- халыкта үз сәламәтлегенә карата сакчыл мөнәсәбәт, сәламәт яшәү рәвешенә омтылыш формалаштыру;
- социаль әһәмиятле авыруларны профилактикалау, гомуми авырулар санын киметү;
- алкогольле продукция, сыра, тәмәке куллануны киметү;
- алкогольле продукцияне чамадан тыш куллануны кисәтү системасының нәтиҗәлелеген арттыру.

Программаның максатларына ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

1. Тәмәке тартуның һәм алкоголь эчемлекләрен куллануның кимүе.
2. Алкогольле эчемлекләр, шул исәптән сыра сату күләмен һәм тәмәке эшләнмәләрен сатып алу чыгымнарын киметү, эшләүче гражданнарның сәламәтлеген саклау, сәламәтлек культурасын формалаштыру өлкәсендә иҗтимагый сәламәтлекне саклау системасын, физик культура һәм спортны, мәгарифне үстерү.
3. Яшәү, уку, хезмәт эшчәнлеге урыны буенча төрле категория халыкның физик культура, спорт белән шөгыльләнүе өчен уңайлы шартлар булдыру.
4. Физик активлыкны һәм сәламәт яшәү рәвешен системалы пропагандалауны оештыру.

Программаны тормышка ашыру вакыты: 2021-2023 еллар.

## III. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

2021 - 2023 елларда программаны финанслауның гомуми күләме 5 502 000 сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

2021 елда - 1 834 000 сум;

2022 елда - 1 834 000 сум;

2021 елда - 1 834 000 сум

Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм тиешле елга һәм план чорына бюджет проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш.

Республика, федераль бюджеттан һәм бюджеттан тыш чыганаклардан средстволар ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк.

## IV. Программаны тормышка ашыру механизмы

Программаны хәл итү өчен түбәндәге чараларны гамәлгә ашыру каралган:

1. Массакүләм мәгълүмат чаралары, Интернет челтәре аша, басма продукция һәм тышкы реклама чаралары аша, сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга юнәлдерелгән мәгълүмати-белем бирү кампанияләре уздыру юлы белән, халыкның мәдәни-күңел ачу тормышы элементлары аша, өлкән яшьтәге халыкның билгеле бер төркемнәрен диспансерлаштыру буенча чараларны актив гамәлгә ашыру юлы белән, тәмәке тарту, алкоголь куллануның сәламәтлеккә начар йогынты ясавы турында халыкка мәгълүмат бирүдә яшьләр, иҗтимагый, дини оешмаларның катнашуын киңәйтү аша сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау.

2. Халыкны тәмәке тартудан баш тартуга мотивлаштыру максатында мәгълүмати кампанияләр һәм массакүләм акцияләр үткәрү.

3. Халыкны алкоголь куллanudан баш тартуга мотивлаштыру максатында мәгълүмати кампанияләр һәм массакүләм акцияләр үткәрү.

5. Тукай районы халкының физик активлык дәрәҗәсен күтәрү, дөрес туклануга өйрәтү, психоэмоциональ басым дәрәҗәсен киметү.

6. Тиешле лицензиядән башка алкогольле продукцияне ваклап сатуны ачыклау һәм булдырмау эшчәнлеген активлаштыру.

7. Алкогольле продукцияне ваклап сатуга куела торган мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен контрольдә тотуны (күзәтчелекне) көчәйтү.

8. Алкогольле һәм спиртлы, шул исәптән өйдә эшләп чыгарылган продукциянең легаль булмаган җитештерүенә һәм әйләнешенә каршы тору чараларын камилләштерү.

9. Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга, халыкның эчкечелеген киметүгә юнәлдерелгән массакүләм акцияләр үткәрү.

10. Халыкка массакүләм мәгълүмат чаралары аша кеше организмына алкоголь куллану зыяны турында хәбәр итү.

11. Наркологик ярдәм күрсәтүче махсуслаштырылган медицина оешмаларын, алкоголь патологиясе белән авыручыларны диагностикалауның, дәвалауның һәм реабилитацияләүнең заманча методикаларын гамәлгә кертүне тәэмин итү.

Программаны гамәлгә ашыру сәламәтлекнең актуаль проблемалары, шул исәптән сәламәт яшәү рәвеше, сәламәтлекне актив саклау һәм ныгыту, культура дәрәҗәсен һәм сәламәтлек потенциалын арттыру буенча халыкның мәгълүматлылыгын арттырырга, Тукай муниципаль районы халкының тормыш сыйфатын һәм уртача гомер озынлыгын арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

Программа чараларының нәтиҗәлелеген бәяләү өчен, түбәндәге күрсәткечләрне кулланырга тәкъдим ителә:

- халык арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча, шул исәптән алкогольле продукция, сыра һәм тәмәке тартуның зыяны турында массакүләм мәгълүмат чараларында публикацияләр саны;
- өлкән яшьтәге халыкның аерым төркемнәрендә диспансеризация узуга җәлеп ителгән гражданнар саны;
- барлык сәбәпләрдән үлүчеләр саны;
- кан әйләнеше системасы авыруларыннан үлүчеләр саны;
- халык арасында физик активлыкның таралуы;
- балаларны һәм яшьләрне физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү дәрәҗәсе;
- алкогольле продукцияне ваклап сату өлкәсендә хокук бозуларның чагыштырма зурлыгы (нәтиҗәлелеге);
- исерек хәлдә кылынган җинаятьләрнең, шул исәптән тикшерелгән җинаятьләрнең чагыштырма зурлыгы;
- алкоголь продукциясе белән агулану белән бәйле үлем дәрәҗәсе;
- сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау буенча массакүләм акцияләр саны;
- гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның гомуми саныннан акциядә катнашучы укучылар өлеше;
- җәйге каникуллар чорында эшкә урнаштырылган укучылар саны;
- алкогольле бәйлелектән стационар дәваланган авыручылар саныннан реабилитация узган алкогольле бәйлелек белән авыручыларның чагыштырма зурлыгы.

Программаның координаторы булып муниципаль район Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге тора, ул тармак бүлекләре һәм идарәләре, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар белән берлектә:

- программа чаралары исемлеген, аларны тормышка ашыру чыгымнарын төгәлләштерү, шулай ук программаны тормышка ашыру механизмы турында билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр әзерли;
- максатчан индикаторлар исемлеген һәм аларны квартал саен бүлүне төгәлләштерә.

## V. Программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны тормышка ашыруның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеге район халкының төрле төркемнәрендә авырулар саны кимүне, халык сәламәтлеген ныгытуны һәм тормыш сыйфатын күтәрүне, сәламәт яшәү рәвешенә, алкогольле продукция, сыра һәм тәмәке куллануны киметүгә юнәлтелгән профилактик чаралар белән халыкны тәэмин итүне күздә тота.

Бәяләү индикаторлары

| күрсәткечләр: | 2021 | 2022 | 2023 |
|---|---|---|---|
| халыкта сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча мәгълүмати-коммуникацион проектларны гамәлгә ашыручы массакүләм мәгълүмат чаралары саны | 4 | 4 | 4 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| өлкән яшьтәге халыкның аерым төркемнәренә диспансеризация узуга җәлеп ителгән гражданнар саны | 8250 | 8250 | 8250 |
| барлык сәбәпләрдән үлүчеләр саны | 500 кеше/1000 кешегә 12,1 | 490 кеше/1000 кешегә 11,9 | 480 кеше/1000 кешегә 11,6 |
| кан әйләнеше системасы авыруларыннан үлүчеләр саны | 280 кеше/ 100 мең кешегә 677.2 | 275 кеше/100 мең кешегә 665,1 | 270 кеше/100 мең кешегә 653,0 |
| халык арасында физик активлыкның таралуы | 51% | 52% | 53% |
| балаларны һәм яшьләрне физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү дәрәҗәсе | 70% | 72% | 75% |
| алкоголь продукциясе белән агулану белән бәйле үлем-китем дәрәҗәсе | 4 кеше/100 мең кешегә 9,7 | 3 кеше/100 мең кешегә 7,3 | 2 кеше/100 мең кешегә 4,8 |
| массакүләм акцияләр саны | 8 | 9 | 10 |
| массакүләм мәгълүмат чараларында (радио, телевидение, матбугат) урнаштырылган мәгълүмати материалларның саны | 6 | 8 | 10 |
| гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның гомуми саныннан акциядә катнашучы укучылар өлеше | 30% | 40% | 50% |
| сәламәтлеккә ярдәм итүче гомуми белем бирү оешмалары өлеше | 50% | 60% | 70% |
| алкогольле бәйлелектән стационар дәваланган авыручылар саныннан реабилитация узган алкогольле бәйлелек белән авыручыларның чагыштырма зурлыгы | 10% | 10% | 10% |

кушымта

**«2021 - 2023 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү» программасын гамәлгә ашыру буенча чаралар**

| № | Чаралар исеме | Финанс чараларын бүлү, еллар буенча (сумнарда) | | | | Финанслау чыганагы | Башкаручы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2021 ел | 2002 ел | 2023 ел | Барлыгы | | |
| I. Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкогольле продукция, сыра һәм тәмәке куллануны киметү буенча оештыру чаралары | | | | | | | |
| 1. | Халыкның суррогат куллануын булдырмау максатыннан, муниципаль район җирлекләрендә алкогольле продукция сатуның айлык мониторингы | | | | | финанслау таләп ителми | Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты |
| 2. | Район территориясендә фальсификацияләнгән алкогольле продукцияне ачыклау буенча системалы планлы тикшерүләр үткәрү | | | | | финанслау таләп ителми | Тукай муниципаль районы эчке эшләр бүлеге |
| 3. | Тәмәке тартуның зыяны һәм нәтиҗәләре турында күрсәтмә мәгълүмат урнаштыру | | | | | агымдагы финанслау | Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге |
| 4. | Балигъ булмаганнарга алкогольле продукция һәм сыра сату очракларын ачыклау, алкогольне вакыт буенча, шулай ук ике төрле билгеләнештәге спиртлы продукция сатуны чикләү буенча мобиль төркем эше | | | | | агымдагы финанслау | Тукай муниципаль районы эчке эшләр бүлеге, район Башкарма комитеты, алкоголь инспекциясенең территориаль бүлеге |
| 5. | Халык арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча, шул исәптән алкогольле продукция, сыра һәм тәмәке тартуның зыяны турында массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмат бастыру | | | | | агымдагы финанслау | «Татмедиа» АҖ филиалы - «Якты юл» («Светлый путь») газетасы редакциясе |
| 6. | Программаның иң мөһим чаралары турында мәгълүматны муниципаль районның рәсми сайтында урнаштыру | | | | | финанслау таләп ителми | Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты |
| 7. | Социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрне һәм | | | | | финанслау таләп | Балигъ |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | балигъ булмаганнарны тикшерү буенча рейдлар үткәрүне оештыру | | | | | ителми | булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия |
| 8. | Профилактика системасы хезмәтләрендә исәтдә торучы гаиләләрнең район мәгълүмат банкын системалы яңарту | | | | | финанслау таләп ителми | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия |
| II. Профилактик чаралар һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча чаралар | | | | | | | |
| 9. | Җәйге каникуллар вакытында 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру | | | | | агымдагы финанслау | «Тукай муниципаль районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ, мәгариф идарәсе |
| 10. | Авыл җирлекләрендә психиатр наркологның планлаштырылган күчмә лекцияләре, темалар:<br>- алкоголь, сыра куллануны профилактикалау;<br>- тәмәке һәм тәмәке катнашмаларын тартуны профилактикалау;<br>- яшүсмерләрнең суицидаль үз-үзләрен тотышын профилактикалау;<br>- наркотикларга бәйлелек факторларын кисәтү | | | | | агымдагы финанслау | «Тукай районы үзәк хастаханәсе» ДАССУ Психиатр нарколог |
| 11. | Акушер гинекологның планлаштырылган күчмә лекцияләре, темалар:<br>- яшүсмер кызлар арасында иртә йөклелекне профилактикалау, гаилә кыйммәтләрен формалаштыру;<br>- хатын-кызлар организмы турында;<br>- аналык муентыгының яман шешен профилактикалау; | | | | | агымдагы финанслау | «Тукай районы үзәк хастаханәсе» ДАССУ Акушер гинеколог |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | - күкрәкнең яман шешен профилактикалау | | | | | | |
| 12. | Инфекционистның планлаштырылган күчмә лекцияләре, темалар:<br>- ВИЧ инфекциясе һәм СПИД;<br>- куркынычсызлык - безнең сайлау. | | | | | агымдагы финанслау | «Тукай районы үзәк хастаханәсе» ДАССУ Инфекционист |
| 13. | Терапевтларның планлаштырылган күчмә лекцияләре, темалар:<br>- эчәклекнең яман шешен профилактикалау;<br>- йөрәк-кан тамырлары авыруларын профилактикалау | | | | | агымдагы финанслау | «Тукай районы үзәк хастаханәсе» ДАССУ Терапевт |
| 14. | Тәмәке тартуның зыяны һәм нәтиҗәләре турында күрсәтмә мәгълүмат урнаштыру | | | | | агымдагы финанслау | «Мәгариф идарәсе» МКУ, мәдәният бүлеге |
| 15. | Ел саен 31 майда «Бөтендөнья тәмәке тартуга каршы көрәш көне» үткәрү, тематик викториналар, конкурслар, иҗади эшләр күргәзмәләре үткәреп, профилактик акция оештыру | | | | | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ | мәдәният бүлеге |
| 16. | Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча мәдәни-массакүләм чаралар үткәрү | 20000 | 20000 | 20000 | 60000 | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ | мәдәният бүлеге |
| 17. | Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен сабантуй | 36000 | 36000 | 36000 | 108000 | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ | мәдәният бүлеге, социаль яклау идарәсе |
| 18. | Китапханәләрдә тәмәке тартуның, алкоголь продукциясен куллануның зыяны турында китап-иллюстрацияле күргәзмәләр оештыру | | | | | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ | мәдәният бүлеге |
| 19. | Алкогольле продукцияне куллануны һәм социаль тискәре күренешләрне профилактикалау буенча түгәрәк өстәлләр, акцияләр үткәрү | 5000 | 5000 | 5000 | 15000 | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ | мәдәният бүлеге |
| 20. | Укучылар һәм аларның ата-аналары арасында педиатрлар, психиатрлар, наркологлар, полиция | | | | | финанслау таләп ителми | «Мәгариф идарәсе» МКУ, |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хезмәткәрләрен җәлеп итеп, балалар һәм яшүсмерләрдә начар гадәтләрне профилактикалау буенча лекцияләр, әңгәмәләр үткәрү | | | | | | «Тукай муниципаль районы үзәк хастаханәсе» ДАССУ |
| 21. | Яшәү урыны буенча төрле яшьтәге халык катнашында физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт-массакүләм чаралары үткәрү | 411700 | 411700 | 411700 | 1235100 | «Тукай муниципаль районының яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы» МБУ | яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| 22. | Районның мәгариф учреждениеләре, авыл җирлекләре арасында физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт-массакүләм эшләрен иң яхшы оештыруга смотр-конкурслар үткәрү | 125000 | 125000 | 125000 | 375000 | «Тукай муниципаль районының яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы» МБУ | яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| 23. | Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» МБУ бүлекләренең спорт секцияләре һәм түгәрәкләре эшен оештыру, аларның матди базасын ныгыту | 170617 | 170617 | 170617 | 511851 | Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» МБУ | Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» МБУ |
| 24. | Балалар һәм яшүсмерләрнең яшәү урыны буенча спорт корылмаларының, кызыксыну буенча клубларның даими эшен, өстәмә белем бирүне тәэмин итү | | | | | агымдагы финанслау | яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| 25. | Яшәү урыны буенча «риск төркеме»нә кергән балалар һәм яшүсмерләр белән эшләүне оештыру | | | | | агымдагы финанслау | яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| 26. | ТР, РФ беренчелекләрендә, чемпионатларында, спорт төрләре буенча бөтенроссия ярышларында һәм турнирларда катнашу (яшәү, туклану, бару чыгымнары) | 786683 | 786683 | 786683 | 2360049 | Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» МБУ | яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 27. | Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларын җиһазлау өчен спорт җиһазлары, кием һәм инвентарь сатып алу | | | | | Республика бюджеты | Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» МБУ |
| 28. | Алкогольле продукцияне системалы рәвештә кулланучы, эш белән тәэмин ителмәгән гражданнар белән шәхси эш, аларны эшкә урнаштыруда ярдәм итү | | | | | агымдагы финанслау | «Тукай муниципаль районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ |
| 29. | «Куркынычсыз тәгәрмәч» уены | 15000 | 15000 | 15000 | 45000 | «Тукай муниципаль районы мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБӨББУ | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 30. | Татарстан Республикасы укучылары арасында спорт туризмы төрләре буенча республика ярышларының муниципаль этабы | 10000 | 10000 | 10000 | 30000 | «Тукай муниципаль районы мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБӨББУ | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 31. | Мәгариф оешмалары укучылары арасында чаңгы туризмы буенча ярышлар | 15000 | 15000 | 15000 | 45000 | «Тукай муниципаль районы мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБӨББУ | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 32. | Спорт туризмы буенча ярышлар «Алтын көз» | 7000 | 7000 | 7000 | 21000 | «Тукай муниципаль районы мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБӨББУ | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 33. | Мәгариф оешмалары укучылары арасында иң | 10000 | 10000 | 10000 | 30000 | «Тукай | «Мәгариф идарәсе» |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | яхшы физик әзерлек конкурсы | | | | | муниципаль районы мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБӨББУ | МКУ |
| 34. | «Бөтен гаилә белән стартка!» эти-әниләр белән спорт бәйрәме | 15000 | 15000 | 15000 | 45000 | «Тукай муниципаль районы мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБӨББУ | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 35. | Татарстан Республикасы мәктәп укучылары спартакиадасы кысаларында мәктәп укучылары арасында республика ярышларында катнашу | 122000 | 122000 | 122000 | 366000 | «Тукай муниципаль районы мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБӨББУ | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 36. | «Кышкы әкият» район кар сыннары конкурсы | 30000 | 30000 | 30000 | 90000 | «Тукай муниципаль районы мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБӨББУ | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 37. | Мәгариф хезмәткәрләренең спорт төрләре буенча спартакиадасы | 30000 | 30000 | 30000 | 90000 | «Мәгариф идарәсе» МКУ | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 38. | Башлангыч сыйныф укучылары өчен күңелле стартлар | 5000 | 5000 | 5000 | 15000 | «Мәгариф идарәсе» МКУ | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 39. | Мәктәп волейбол лигасы | 20000 | 20000 | 20000 | 60000 | «Мәгариф идарәсе» МКУ | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 40. | **Барлыгы** | **1834000** | **1834000** | **1834000** | **5502000** | | |